**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының**
**Гулкин авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**№37** **28.07.2021 ел**

**«Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 12 ноябрендәге 78 номерлы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Уставы нигезендә, Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» 2013 елның 12 ноябрендәге 78 номерлы Зәй муниципаль районының Гулкин авыл җирлеге Советы карарына (07.08.2014 ел №112, 02.03.2015 ел № 140, 21.05.2018 ел № 102, 14.11.2019 № 156) карарлар нигезендә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 бүлекнең 2 абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

1.2. 20 бүлекнең 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җирле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына) бюджет турында карар проекты кертелгәннән соң кабул ителгән җирлек Советының муниципаль хокукый актлары нигезләмәләре агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә, агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә, чираттагы финанс елында исәпкә алына."

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының "Авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет Рәисе** **С.Д.Инькова**